СОВЕТ
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: Mcel.Drz@tatar.ru,

**РЕШЕНИЕ** *с.Малая Цильна* **КАРАР**

2021 нче елның 29 нчы октябре № 11/2

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Кече Чынлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәнең 4 бүлеге нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, әмма 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел.

3.Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмәнең 4 бүлеге нигезләмәләре 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кече Чынлы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Ш.Халитов